**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

30 октябрь, 2024 ел　　　　Мәләкәс авылы　　　　№ 22

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Яңа Җирекле авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районының «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2024 елның 10 ноябренә 16:00 сәгаттә Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Яңа Җирекле авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2025 елда яшәү урыны буенча Мәләкәс авыл җирлеге Яңа Җирекле авылында территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, һәм РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взнослар түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдереләчәк, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

-торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

-су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;

-торак пункт территориясен төзекләндерү

«ӘЙЕ»　　　　«ЮК».

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай районы, Яңа Җирекле авылы, Үзәк урам, 1.
4. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Мәләкәс авыл җирлеге Башлыгы Р.В.Иванов